КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 ноябрь г.Казань № 1022

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының һөнәри авария-коткару хезмәтләрен һәм һөнәри авария-коткару формированиеләрен җиһазландыру табелен раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1029 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының һөнәри авария-коткару хезмәтләрен һәм һөнәри авария-коткару формированиеләрен җиһазландыру табелен раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1029 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасы эзләү-коткару хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесен авария-коткару эшләренең игълан ителгән төрләрен үтәүне тәэмин итә торган авария-коткару чаралары белән тәэмин итү нормаларын раслау турында»

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасы эзләү-коткару хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесен авария-коткару эшләренең игълан ителгән төрләрен үтәүне тәэмин итә торган авария-коткару чаралары белән тәэмин итү нормаларын расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр

министрлыгына «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы  Татарстан Республикасы эзләү-коткару хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә  каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының һөнәри  авария-коткару хезмәтләрен һәм һөнәри авария-коткару  формированиеләрен җиһазландыру табелендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы  Татарстан Республикасы эзләү-коткару хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесен авария-коткару эшләренең игълан ителгән төрләрен үтәүне тәэмин итә торган авария-коткару чаралары белән тәэмин итү нормалары»;

2 графаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авария-коткару эшләренең игълан ителгән төрләрен үтәүне тәэмин итә торган авария-коткару чаралары атамасы».

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры А.В.Песошин